ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СЕЛЕНГУШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СӘЛӘНГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» август 2025 ел № 13

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге территориясендә терекөмешле кулланылган лампаларны туплау урыннары турында" 2023 елның 5 июнендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә «Яктырткыч җайланмалар, электр лампалары, тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау өлешендә һәм аларны урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булганда җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында (2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карар белцн кертелгән үзгәрешләр белән)», Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге территориясендә терекөмешле кулланылган лампаларны туплау урыннары турында» 2023 елның 5 июнендәге 6 номерлы карарының 2 пунктына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш территориясендә, әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру, шулай ук мәгълүматны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге биналарында мәгълүмат стендларында (стойкаларда) урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.».

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм түбәндәге

адрес буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында: http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Н. Пинин